**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.10.2018 г.Мензелинск № 1175

Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ирекле (волонтерлык) эшчәнлеге, ирекле (волонтерлык) оешмалар белән үзара бәйләнеше Тәртибе турында

06.10.2003 елда кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары” №131-ФЗ Федераль законы, 1995 елның 11 августында кабул ителгән “Хәйриячелек эшчәнлеге һәм ирекләләр (волонтерлык) турында”гы №135-ФЗ Федераль законының 17.3 маддәсе, 4 нче өлеше нигезендә. Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Беркетелгән Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ирекле (волонтерлык) эшчәнлеге, ирекле (волонтерлык) оешмалар белән үзара бәйләнеше Тәртибен расларга.
2. Гамәлдәге Карар рәсми төстә басылырга тиеш.
3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче урынбасары Н.Г.Бикеева.

Кушымта
ТР Минзәлә муниципаль район
башкарма комитеты Карарына
от 17.10.2018 №1175

Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ирекле (волонтерлык) эшчәнлеге, ирекле (волонтерлык) оешмалар белән үзара бәйләнеше Тәртибе

1. Гамәлдәге Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән максатларда, эшләрне һәм хезмәт күрсәтүне бушлай башкару формасында ирекле эшчәнлек ирекле (волонтерлык) эшчәнлек буларак кабул ителә.

2. Җирле үзидарә органнары иреклеләр (волонтерлык) эшчәнлеген башкаруга ирекле затларны (волонтерларны) җәлеп итәргә хокуклы.

3. Ирекле (волонтёрлык) эшчәнлеге түбәндәге максатларда башкарыла:

- гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү һәм аларны яклау (азкеремлеләрнең матди хәлен яхшыртуны, эшсезләрне, физик һәм интеллектуаль үзенчәлекләре, башка сәбәпләр аркасында үз хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен мөстәкыйль тормышка ашырырга сәләтсез булган инвалидларны һәм башка затларны социаль тернәкләндерү;

- стихияле бәла-каза нәтиҗәләрен, экологик, сәнәгать яисә башка катастрофаларны җиңеп чыгуга, бәхетсезлек очракларын булдырмауга халыкны әзерләү өчен;

- стихияле бәла-казалар, экологик, сәнәгать яисә башка катастрофалар, социаль, милли, дини конфликтлар нәтиҗәсендә зыян күрүчеләргә, репрессия корбаннарына, качакларга һәм күчеп китәргә мәҗбүр булучыларга ярдәм күрсәтү өчен;

- халыклар арасында тынычлык, дуслык һәм килешүне ныгытуга, социаль, милли, дини конфликтларны булдырмауга ярдәм итү өчен;

- җәмгыятьтә гаиләнең абруен һәм ролен ныгытуга ярдәм итү өчен;

- ана булу, балачак һәм ата булуны яклауга ярдәм итү өчен;

- мәгариф, фән, мәдәният, сәнгать, агарту, шәхесне рухи яктан үстерү өлкәсендә эшчәнлеккә ярдәм итү өчен;

- граҗданнарның сәламәтлеген саклау һәм профилактика, шулай ук сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, гражданнарның мораль-психологик хәлен яхшырту өлкәсендә эшчәнлеккә ярдәм итү өчен;

- физик культура һәм спорт (профессиональ спорттан тыш) өлкәсендә, бушлай эшләр башкару һәм физик затлар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү формасында физкультура һәм спорт чараларын уздыруда һәм (яисә) оештыруда катнашу эшчәнлегенә ярдәм итү өчен;

- әйләнә-тирә мохитне саклау һәм хайваннарны яклау өчен;

- тарихи, табыну урыны, мәдәни яисә табигатьне саклау әһәмиятенә ия булган биналарны, обектларны һәм территорияләрне саклау һәм тиешенчә тәртиптә тоту өчен;

- гадәттән тыш хәлләрдән саклау, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм белемнәрне пропагандалау өлкәсендә халыкны әзерләү өчен;

- ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, караучысыз балаларны, авыр тормыш хәлендә калган балаларны социаль тернәкләндерү өчен;

- бушлай юридик хезмәт күрсәтү һәм халыкка хокукый белем бирү өчен;

- ирекле (волонтерлык) эшчәнлеккә ярдәм итү өчен;

- караучысызлыкны профилактикалау һәм балигъ булмаганнарның хокук бозуларын булдырмау буенча эшчәнлектә катнашу өчен;

- балаларның һәм яшьләрнең фәнни-техник, сәнгать иҗаты үсешенә ярдәм итү өчен;

- балаларның һәм яшьләрнең патриотик, рухи-әхлакый тәрбиясенә ярдәм итү өчен;

- иҗтимагый әһәмияткә ия булган яшьләр инициативаларына, проектларга, балалар һәм яшьләр хәрәкәтләренә, балалар һәм яшьләр оешмаларына ярдәм итү өчен;

- социаль рекламаны җитештерү һәм (яисә) тарату эшчәнлегенә ярдәм итү өчен;

- гражданнарның үз-үзләрен тотышының социаль куркыныч формаларын профилактикалауга ярдәм итү өчен.

4. Җирле үзидарә органнары, муниципаль учреждениеләр килешү төзү юлы белән ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручы белән үзара элемтәне башлап җибәрергә хокуклы.

5. Үзара бәйләнешне тәэмин итү максатларында оештыручылар ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген башкару өчен җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль учреждениеләргә язмача тәкъдим җибәрергә хокуклы. Ирекле (волонтерлык) эшчәнлек оештыручының тәкъдимендә: исем-фамилиясе, атасының исеме (булган очракта) һәм җитәкчелекнең һәм вәкилләренең контактлары; дәүләт теркәве турында (юридик затлар өчен) мәгълүматлар; “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияле челтәрдә рәсми сайт адресы; ул башкара торган эшчәнлек төрләренең тасвирланган исемлеге булырга тиеш.

6. Ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының күрсәтелгән тәкъдимнәрен карау срогы 20 эш көненнән артмаска тиеш.

7. Хуплау турында карар чыгару формасында башкарылырга тиеш булган, бердәм эшчәнлек турында килешү проекты беркетелгән, яисә муниципаль учреждение хаты белән рәсмиләштерелгән, тәкъдимнән нигезле баш тартылган ирекле эшчәнлекне оештыручының тәкъдимнәренең муниципаль учреждение тарафыннан каралу нәтиҗәләрен рәсмиләштерү турындагы тәкъдимнәр бер көн эчендә ирекле (волонтерлык) эшчәнлекне оештыручы адресына (мөмкин булганда, электрон почта аша) җибәрелә.

8. Муниципаль учреждение ирекле (волонтерлык) эшчәнлек башкару турындагы тәкъдимнәрне кире каккан очракта, ирекле (волонтерлык) эшчәнлекне оештыручы муниципаль учреждениенең оештыручысы (учредителе) булган җирле үзидарә органына шундый ук тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

9. Ирекле (волонтерлык) оешмалары бердәм эшчәнлек турында җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр белән килешү төзергә хокуклы.

10. Килешүләрне карау срогы ирекле эшчәнлек башкару буенча тәкъдимнәр расланган датадан башлап, 14 эш көненнән артык була алмый.

11. Бердәм эшчәнлек турында килешүне раслау барышында муниципаль учреждение һәм ирекле (волонтерлык) оешма арасында капма-каршылык килеп туган очракта, ирекле (волонтерлык) оешма яисә учреждение оештыручысы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

12. Капма-каршылыклар ике як катнашында карала һәм. Кирәк булган очракта, җирле үзидарә органы каршындагы Иҗтимагый совет һәм муниципаль дәрәҗәдә булдырылган башка киңәшү органнары вәкилләрен җәлеп итеп карала.

13. Бердәм эшчәнлек турында муниципаль учреждение һәм ирекле (волонтерлык) оешма арасында килешү төзегәндә, учреждение ирекләләр (волонтерлар) һәм ирекләләр эшчәнлеген оештыручылар вәкилләре белән үзара бәйләнеш өчен җаваплы хезмәткәр билгеләргә бурычлы.

14. Учреждение һәм ирекле (волонтерлык) эшчәнлекне оештыручының бердәм эшчәнлеге турында килешүләре, башкарыла торган ирекле эшчәнлек спецификасын, бердәм эшчәнлекнең предметын һәм максатларын, 1995 елның 11 августында кабул ителгән “Хәйриячелек эшчәнлеге һәм иреклелек (волонтерлык) турында”гы №135-ФЗ Федераль законының 17.1-17.2 маддәләрендә билгеләнгәнчә, якларның хокукларын һәм бурычларын, йомгаклау положениеләрен кертеп урнаштыруны күздә тотарга тиеш, шул исәптән, түбәндәге положениеләрне дә кертеп:

1) Ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының хокуклары:

- эшчәнлек формаларында учреждение белән килешенгән учреждение биналарында һәм территориядә ирекләләр эшчәнлеген башкаруга;

- төзекләндерү буенча эш уздыру һәм учреждение территориясе торышын яхшырту, учреждение биналарында ремонт уздыру буенча эш башкаруга.

2) Ирекле (волонтерлык) эшчәнлекне оештыручының бурычлары:

- учреждениегә җәлеп ителгән белгечләрне, хезмәткәрләрне һәм/яисә ирекләләрне (волонтерларны) исем-фамилияләрен, атасының исемен күрсәтеп (булган очракта), кирәк булганда – башка мәгълүматларны (якларның килешүе буенча) тәкъдим итү, шул исәптән, а) үзенчәлекле һөнәри күнекмәләр булу турында;

б) вәкаләтле вәкил билгеләргә һәм язмача мөрәҗәгатьтә бу турыда учреждениегә хәбәр итәргә;

в) Россия Федерациясе законнары нигезендә, килешү башкару нәтиҗәсендә билгеле булган конфиденциаль һәм персональ мәгълүматкә карата таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү;

г) учреждение эшен, шул исәптән учреждениенең эчке тәртибе кагыйдәләрен регламентлаучы хокукый нормаларның үтәлешен тәэмин итү;

д) учреждение тәкъдим иткән биналарны, саклау урыннарын, техник чараларны, җиһазларны тиешле санитар-гигиеник һәм техник хәлдә тоту;

е) учреждение белән аның территориясендә клиентлары катнашында башкару планлаштырылган чараларны, планлаштырылган чараларны уздыру планын килешенергә;

ж) учреждениегә башкарылган эшләр һәм чаралар уздыру нәтиҗәләре турында отчет тапшыру;

з) психологик ярдәм, психологик тернәкләндерү тәкъдим итүне тәэмин итү;

и) ирекле (волонтерлык) эшчәнлеге башкарганда ирекле затның тормышына һәм сәламәтлегенә килгән зыянны кайтаруны тәэмин итү.

3) Учреждение хокуклары:

- ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыга иреклеләрне (волонтерларны) җәлеп итү ихтыяҗы турында хәбәр итәргә;

- ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыны, ирекледәрне (волонтерларны) ярдәм белән тәэмин итү.

4) Учреждение бурычлары:

- биналар бирүне, шулай ук ирекледәр (волонтерлар) эшчәнлеген тәэмин итү өчен техник чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итәргә;

- ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген башкару өчен тәүлек буе яисә билгеләнгән вакытка мөмкинлекләр һәм шартлар бирелүен тәэмин итәргә;

- ирекле (волонтерлык) эшчәнлек алып бару белән бәйле куркыныч һәм чикләүләр, учреждение эшен регламентлаучы хокукый нормалар, үтәлеше ирекле (волонтерлык) эшчәнлек оештыручысыннан таләп ителгән тиешле режим таләпләре һәм башка кагыйдләр турында хезмәттәшлек турында ирекле (волонтерлык) эшчәнлек оештыручысы белән килешү төзегәнче язмача хәбәр итәргә, шулай ук әлеге нормалар һәм кагыйдәләрдәге үзгәрешләр турында үзвакытында хәбәр итәргә;

- бергәләшеп эшләү барышында килеп туган мәсьәләләрне оператив хәл итү өчен ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының вәкилләре белән эш буенча вәкаләтле хезмәткәрне билгеләргә.

5) Йомгаклау положениеләре:

- килешүне үтәү барышында килеп туган проблемалар һәм авырлыклар турында бер-берсенә үзвакытында хәбәр итү, шулай ук ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының эшчәнлек нәтиҗәләрен бергәләп тикшерү һәм бәя бирү ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының һәм учреждениенең бурычлары;

- килешүнең көченә керү, аны озайту һәм өзү шартлары, бәхәсләрне чишү, шул исәптән, зарурлык туганда, учреждениенең оештыручысы (учредителе) булган җирле үзидарә органын җәлеп итү.

15. Җирле үзидарә органнары 11.08.1995 елда кабул ителгән №135-ФЗ һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында каралган формаларда ирекле (волонтер) эшчәнлеген башкара.